РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075 ,Республика Татарстан, Сабинский район, с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы, Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.08.2025

КАРАР
№45

**Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитетының 11.06.2014 №27 карары белән расланган Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» һәм ««Элемтә турында» Федераль законның 6 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 23.07.2025 ел, №251-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 11.06.2014 ел, №27 карары белән расланган Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4. пунктының 2.4.1 подпунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә «, элемтә линияләре һәм элемтә корылмалары»;

1.2. 2.4. пунктының 2.4.2 подпунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә «, элемтә линияләренә һәм элемтә корылмаларына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмат-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында

http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адрес буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Явлаштау авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев